ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“09” ноябрь 2021 ел Боерган авылы № 14

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Боерган авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Боерган авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Боерган авылында 2021 елның 19 нояберендә 18.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

“Боерган авыл җирлегенең Боерган авылы территориясендә 2022 елда балигъ булган, Боерган авыл җирлегенең Боерган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Боерган авылы Новая урамы буенча юл төзекләндерү;
- Тойгузино, Мирная урамнарында сууткәргеч челтәрен төзекләндерү
- янгын сүндерү машинасы тора торган гаражның түбәсен төзекләндерүне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме.”

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Боерган авылы, Тойгузино урамы, 1А йорты каршында гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Боерган авыл җирлеге Башлыгы Г.Г.Минакова